# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№11 (735) 11 июнь 2021 ел (1442, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ



Шәүвәл аеның 24 нче көнендә (5 нче июньдә), Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1099 еллыгына багышланган «Изге Болгар җыены» узды. Бәйрәмдә Мәскәүдән күпсанлы рәсми кунаклар, Татарстан Республикасы җитәкчелеге, мөселман дин әһелләре катнашты.

Тантаналы ачылышта Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, республикабыз мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия мөселманнарының Дини җыены рәисе Әлбир Крганов, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Дамир Мөхетдинов, шулай ук башка күренекле мөселман дин әһелләре бар иде. Форумда мәртәбәле кунаклардан ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев, "Россия – Ислам дөньясы" стратегик күзаллау төркеме рәисе урынбасары Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры урынбасары, "Милли Шура" рәисе Васыйл Шәйхразиев, РФ Президентының Эчке сәясәт идарәсенең дини оешмалар белән хезмәттәшлек департаменты башлыгы Евгений Ерёмин, Казан һәм Татарстан Митрополиты Кирилл һ.б. катнашты.

Марат Хөснуллин фестивальдә катнашучыларны РФ хөкүмәте рәисе һәм шәхсән үз исеменнән сәламләп, республика җитәкчелегенә 1100 ел элек нигез салынган, бөтен ил өчен шундый мөһим булган чара уздырганы өчен рәхмәт белдерде. Рөстәм Миңнеханов, РФ Президенты адресына рәхмәт сүзләрен белдереп, 1100 еллыкның гомумфедераль вакыйга булуын һәм бәйрәм чараларының Казан, Татарстан һәм Болгар белән генә чикләнмәячәген, ә Россия күләмендә узачагын ассызыклады. Минтимер Шәймиев исә бу тарихи вакыйганы бәйрәм итү Россия күләмендә Ислам динен тану дигәнне аңлата, диде. РФ Президентының Эчке сәясәт буенча идарәсенең дини оешмалар белән хезмәттәшлек департаменты башлыгы Евгений Еремин билгеләп үткәнчә, бүген Изге Болгар нәкъ менә Болгар җирендә 1000 елдан күбрәк вакыт элек кабул ителгән Ислам фикере, ислам традицияләре белән балкый.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фестивальдә катнашучыларга Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуның әһәмиятен генә аңлатып калмыйча, туган телне сакларга һәм халык санын алу вакытында милли үзенчәлекләрне истә тотарга чакырды.

Изге Болгар җыены уңаеннан күптөрле бәйрәм чаралары: дини җырлар концерты, "Кече манара" янында тәүбә кылу чарасы, Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәр осталарының күргәзмәсе, билбау көрәше буенча Бөтенроссия турниры узды. Көн дәвамында Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгының барлык объектлары да бәйрәм кунакларына хезмәт күрсәтте. Шулай ук Изге Болгар җыенында «Язу тарихы»на багышланган интерактив мәйданчык эшләде. Анда урта гасырда болгар-татар язуы, каләм, каллиграфия үзенчәлекләре турында кызыклы мәгълүмат алу мөмкинлеге булды.

Чараның кульминациясе зур манара янындагы борынгы Җәмигъ мәчете хәрабәләре янында җәмәгать белән өйлә намазын уку булды.

Болгар җыены кысаларында Нәзарәт тарафыннан да кызыклы чаралар уздырылды. Иртәнге сигездә, халыкны чакырып, Истәлек билгесе янында Коръән уку һәм мөнәҗәтләр әйтү башланып китте. Биредә Татарстан мөфтиенең шәкерте, Коръән-хафиз Сәидкамал Суюнов чыгыш ясады. Көн дәвамында Нәзарәт вәкилләре намаз уку тәртипләренә багышланган дәресләр үткәрде, хатын-кызлар өчен яулык бәйләү, ир-атлар өчен чалма чорнау буенча мастер-класслар узды, "Хозур" нәшрияты үз басмаларын дин кардәшләребезгә тәкъдим итеп, сату нокталарында эшне киң җәелдерде, нәшрият хезмәткәрләре халыкны ел дәвамында эшләнгән бушлай мобиль кушымталар белән таныштырды. Татарстан мөфтиятенә караган сигез мәдрәсә, РИИ, КИУның кабул итү комиссиясе вәкилләре абитуриентларның сорауларына җавап бирде, укыту программалары, укырга керү шартлары хакында сөйләде. Мөфтиятнең шәригать мәсьәләләре бүлеге хезмәткәрләре дога кылу һәм йолаларны дөрес итеп башкару тәртипләре буенча консультацияләр бирде. Изге Болгар җыены кысаларында һөнәри сәнгать ярминкәләре, хәләл ризыклар сату нокталары оештырылды.

*(ТР МДН хәбәрләреннән)*

## МӨЭМИНЛЕК БИЛГЕСЕ



Аллаһы Тәгаләдән курку — хикмәтнең нигезедер. Балаларына мал җыеп та, Аллаһы Тәгалә каршысына фәкыйрь барган кешеләр — бәхетсезләрдер. Усаллыктан кайгыру, яхшылык өчен сөенү— мөэминлек, ягъни ислам диненгә кеше булу билгеседер. Аллаһы Тәгалә биргән дәүләтне балаларыгызны вә гаиләгезне тәрбияләүдән кызганмагыз. Кешеләрне яманларга ниятләгәндә, үз хәлегезне үзгәртегез. Фарызлардан, ягъни үтәлергә тиешле бурычлардан элек өстәмәләре белән мәшгуль булмагыз. Серегезне саклаган вакытыгызда ихтыярыгыз кулыгыздадыр. Бер-берегез белән дус булыгыз, йөрешегез, ләкин күрше белән булашмагыз.

Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә, ягъни муллыкларына-байлыкларына шөкер-рәхмәт вә кайбер вакыт бирелгән бәлаләренә сабыр итегез. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте-мәрхәмәте сабыр итүчеләргә булуын онытмагыз!

**Риза ФӘХРЕДДИН** *("Әхлак гыйлеме"ннән)*

## *БЕРГӘ БУЛЫЙК!*

Хөрмәтле укучыларыбыз!




"Ислам нуры" газетасы белән бергә булганыгыз өчен зур рәхмәт сезгә. Киләсе яртыеллыкка язылу өчен почта бүлекчәләрендә "Пресса России" каталогының 1 нче томын сорагыз, "Религия. Философия. Социология. Психология" бүлегендә 54149 индексы белән теркәлгән. Алдагы айларда да бергә булыйк!

# ЯШӘҮ ЯМЕ - КҮҢЕЛ ТЫНЫЧЛЫГЫНДА

*(Ахыры. Башы газетаның алдагы санында)*

**Аллаһы Раббыбыз бөтен кешелек дөньясына мөрәҗәгать итеп, яшәешнең төп кануны булган Коръәни Кәримдә: «Явызлыкка яхшылык белән җавап бир», - ди. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә: «Аң булыгыз! Мөэмин кеше кем икәнлеге хакында хәбәр биримме? Мөэмин шул - кешеләр аннан үзләренең маллары һәм үзләре хакында имин дип белерләр», - дигән. Күргәнебезчә, хәдистә башка мөэминнәр дими, башка кешеләр, ди. Димәк, теленә, диненә, төсенә, холкына карамыйча, һәр кеше үзен имин дип белә.**

«Мөселманның теленнән дә, кулыннан да башкалар сәламәт булыр (монда да башка мөселманнар гына дими, башкалар дип барлык кешелек дөньясын атый. Ислам, сәлам, мөселман, сәламәтлек бер тамырдан - тынычлык сүзеннән алынган). Мөҗәһит - Аллаһы Тәгаләгә буйсыну турысында нәфесе белән сугышыр (безгә әле башкаларны тикшергәнче, сүккәнче, алар белән көрәшкәнче, үзебезнең очсыз-кырыйсыз нәфесебезне бераз гына булса да чикләү өчен тырышырга кирәк). Мөһаҗир бозык һәм гөнаһ эшләрен ташлар (динсез кардәшләреннән, ата-анасыннан, күршеләреннән аерылыр, туган җиреннән, туган теленнән баш тартыр, ваз кичәр дими. Кайберәүләр шуны егетлеккә саныйлар, ширектән качу дип күрсәтәләр)» (хәдис).

Мин бу хәдис белән алда әйтелгән Коръән аятен, зур итеп язып, һәр мәчетнең эченә элеп куяр идем.

Ачуның асылы - ут. Ут сүрелсен, сүнсен өчен, аңа өстәмәү дә җитә. Шуңа күрә Аллаһы Раббыбыз: «Явызлыкка яхшылык белән җавап бирегез», - ди. Шулай итеп кенә явызлыкны җиңеп яки киметеп була. Һәр каршылык каршылык, һәр явызлык явызлык уята. Сабыр итәргә, җавап кайтармаска, җавап кайтарсаң да, яхшылык белән җавап кайтарырга кирәк.

Аллаһы Раббыбыз: «Ачуыгызны эчкә алыгыз, дошманнарыгызны гафу итегез. Яхшылык кылучы әнә шундый мөэминнәрне Аллаһы сөядер», - ди. Раббың каршында сөекле буласың килсә, яхшылык кыл, әмма әлеге эшне һәркем эшли алмый. Бу турыда Аллаһы Раббыбыз: «Ләкин бу эшне һәр кеше эшли алмас, мәгәр чын иманлы, сабыр мөэминнәр генә эшли алырлар, вә явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, мәгәр олуг бәхетле кешегә генә бирелер», - ди. («Фүссыйләт» сүрәсе, 35 нче аять).

Кайвакыт кешеләрне сабырлыкка чакырсаң, явызлыкка яхшылык белән җавап кайтарырга кушсаң: «Аның нәтиҗәсен күрергә бәлки гомер дә җитмәс, бүген үк җавап кайтарсаң, җәза бирсәң - күңел тынычлана», - дип, җавап кайтаралар. Юк, синең күңелең тынычланмый, шайтаның гына тынычлана. Бу дөнья белән генә бетми бит, ахирәт тә бар. Кемдер эшләгән ялгышлыгының нәтиҗәсен сөенечен бу дөньяда күрә алмый икән, аның әҗере теге дөньяда булачак, моның 100 процент гарантиясе бар. Бу дөньяда әҗерен күрсәң, теге дөньяда әҗере буламы, юкмы - анысы билгесез. Явызлыгы өчен җавап бирми калганнар да мәңгелек дөньяда газабын күрәчәк. Вакытлы гына бу дөньяда җәзасын күрми калганнар үкенәчәкләр. Аллаһы Раббыбыз да: «Хәйләләп кемнедер алдаганнар ничек алданганнарын соңыннан аңларлар», - ди. Вакытлы гына бу дөньяда, вакытлы гына бер сөенеч өчен мәңгелегеңдә утка керү акыллылык та, иманлы булу да, сабырлык та билгесе түгел. Шуңа күрә Аллаһы Раббыбыз: «Бу эшне чын иманлы сабыр мөэминнәр генә эшләр», - ди. Күңеле саф һәм тәртиптә булган кешегә әлеге эшне эшләү авыр түгел, явызлыкка яхшылык белән җавап кайтара алу - иң зур бәхет. Бу синең туры юлда булуыңны, рәхмәт фәрештәләренең рәхмәтенә ирешүеңне, Раббың каршында сөекле бәндә икәнлегеңне һәм Аллаһының күңел тынычлыгы дигән иң зур нигъмәтенә ирешүеңне күрсәтә, әгәр алай түгел икән, Аллаһы Раббыбыз: «Әгәр явызлык итүчегә изгелек итәргә шайтан сиңа ирек бирмәсә, шайтанның вәсвәсәсеннән Аллаһыга сыен. Ул сине шайтан вәсвәсәсеннән саклар, аннары явызлыкка каршы изгелек итә алырсың. Ул - Аллаһы Ишетүче вә Белүчедер», -ди. («Фүссыйләт» сүрәсе, 36 нчы аять).

*Аллаһы Раббыбыз: «Ачуыгызны эчкә алыгыз, дошманнарыгызны гафу итегез. Яхшылык кылучы әнә шундый мөэминнәрне Аллаһы сөядер», - ди.*

Син явызлыкка яхшылык белән җавап кайтара алмыйсың икән, кем гаепле? Шайтанмы? Синең шайтан вәсвәсәсендә булуың ни сәбәптән? Әйдә, уйлап карыйк. Шайтанның да Аллаһы Тәгаләнең рөхсәтеннән башка эш эшләгәне юк.

Шайтан, Адәмгә сәҗдә кылудан баш тартып, Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм калгач, Раббыбыздан кешелек яшәгән кадәр гомер сорый һәм: «Мин аларны төрле яктан килеп адаштырырмын, сәҗдәгә лаек түгеллекләрен исбатлармын», - ди. Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте белән аңа бу мөмкинлекне бирә. Шайтан моның белән генә чикләнми: «Куәтемне арттыр», - ди. Аллаһы Раббыбыз: «Бер кеше туган саен бер шайтан туар», - ди (һәркайсыбызның шайтаны бар. Бозыклык эшләп аны куәтләндермик. Дөньяга килгән бала да шуны күреп елый). Шайтан кабат: «Куәтемне арттыр», - ди. Аллаһы Раббыбыз: «Кешенең кан тамырларында йөреп, вәсвәсә кылырсын”, - ди (ураза - кан тамырларында шайтанга йөрергә киртә булып тора). Шайтан янә: «Куәтемне арттыр», - ди. Аллаһы Раббыбыз: «Якыннары булып фикереңне җиткерерсең», - ди (шайтан хатының, әти-әниең, күршең булып та сөйләшергә мөмкин. Ялганны хактан аралар өчен чиста калеб кирәк).

Тәфсир риваятьләреннән күренгәнчә, бу сөйләшүне Атабыз (г-м) дә ишетә һәм Раббыбыздан шайтанга каршы тору өчен куәт сорый. Аллаһы Раббыбыз: «Мин пәйгамбәрләр җибәрермен, китаплар иңдерермен. Кем пәйгамбәргә ияреп Коръән кушканча яшәсә, аларга шайтанның көче җитмәс», - ди. Адәм (г-м) кабат: «Куәтемне арттыр», - ди. Аллаһы Раббыбыз: «Бер кеше туган саен ике сакчы фәрештә туар», - ди. Тиешсез киемнән йөрсәк, тиешсез ризык ашасак, тиешсез сүз сөйләшсәк, Аллаһы рәхмәте булган сакчы фәрештәләр бездән бизәләр. Адәм (г-м) кабат: «Куәтемне арттыр», - ди. Аллаһы Раббыбыз: «Бер яхшылык ун булып язылыр, гөнаһлар арттырылмас», - ди (Аллаһының рәхмәте шулкадәр киң, изге айларда (рәҗәб, шәгъбән, мөхәррәм), изге көннәрдә (Гашура, Гарәфә...), изге кичәләрдә (Мигъраҗ, Бәраәт...) бер яхшылык йөз булып, рамазан аенда меңгә кадәр, Кадер кичәсендә утыз меңгә кадәр языла). Адәм (г-м) кабат «Куәтемне арттыр», - ди. Аллаһы Раббыбыз: «Тәнеңдә җаның бар чакта тәүбә капкасын япмам», - ди.

Шайтан вәсвәсәсенә бирешәбез, күңелебез тыныч түгел икән, димәк тәкъвалыгыбыз җитми, гыйбадәтләребезне арттырыйк. Бүген әле үзебез намазлык өстендә булсак та, күңелебезне намазлыкка бастыра алганыбыз юк. Коръән укыйбыз, кыямда торабыз, рөкүгъ, сәҗдәләр кылабыз. Күңел кайда? Үзебез мәчеттә булсак та, күңел әллә кайларда. Шуның өстенә әллә кемнәрне, әллә нәрсәләрне сүгәбез, гаеплибез, аннан да яманы - кяфергә чыгарабыз. Аллаһы Раббыбыз безгә үзебезне бәяләр өчен гүзәл бер үлчәм бирде. Әле син явызлыкка яхшылык белән җавап бирә аласыңмы? Юк икән, үзеңне тәрбиялә, гүзәл әхлакка ireш. Әнә шул гүзәл әхлагың башкаларга да туры юлны табарга, тәүбәгә килергә булышыр. Олыны олы итә, әмирләргә, имамнарга итагать итә, үзеңне түбәнчелекле тота белмәсәң, башкаларга хөрмәт белән карамасаң, сиңа әле камиллеккә бик ерак. Башкаларга хөрмәт күрсәтмәгән - Аллаһыны хөрмәт итә алмый. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Аллаһы Раббыбыз сезгә әниегезгә караганда да якын, табигать - Аллаһының гаиләсе», - дигән.

Балаңның начар ягын беләсең, әмма аны сиңа кемдер әйтә икән - рәхәт түгел. Кемне генә сүксәк тә, кемгә генә зыян салсак та, Аллаһының рәхмәтеннән ерагаябыз.

Һәркайсыбызга, телләребезгә, күңелләребезгә сабырлык биреп, хәтта начарлык кылучыларга да яхшылык кылып яшәргә Аллаһы Раббыбыз насыйп итсә иде. Бу дөньяда бергә булган кебек, җәннәт нигъмәтләре белән дә бергә нигъмәтләнергә язса иде.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
*Татарстанның баш казые*

# ҖОМГА КӨН

Динебездәге иң изге көннәрдән берсе - җомга көндер, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисе буенча, җомга көн гает вә Гашура көннәреннән олырактыр. Җомга көн - мөселманнарның бәйрәмедер. Бу көннең өйлә сәгатендә җәмәгать белән укыла торган җомга намазы бар. Башка намазларга мәчеткә бара алмаса да, атнага бер мәртәбә, мәчеткә барып, бу намазны уку, хөтбә һәм вәгазь тыңлау мөселманнарга фарыздыр. Сәбәпсез җомга намазын калдыру - зур гөнаһтыр.

Җомга көнне, балаларга бүләкләр алып, аларны шатландыру, ярлыларга ярдәм бирү, каберләрне зиярәт итү, госел-тәһарәт алып, яхшы, матур вә пөхтә киемнәр киеп, мәчеткә бару, кардәшләр белән күрешү - дини гадәтләребездәндер.

Кайбер мөселман дәүләтләрендә җомга көн ял көне итеп игълан ителгән. Моның максаты - кешеләр, җомга намазында катнашып, бу изге көннең үз өлешләрен алсыннар, димәктер. Ләкин җомга көн, яһүдиләрдәге шимбә көн вә христианнардагы якшәмбе кебек, эштән калу көне түгел. Җомга көнне, җомга намазы сәгатеннән башка вакытларда эш эшләргә ярый. Пәйгамбәребезнең хәдисе буенча, җомга көнендә кылынган догаларны Аллаһы Тәгалә кабул итә торган бер сәгать бар. Ләкин бу сәгатьнең кайсы вакытка туры килүен беркем дә белми. Моның максаты - мөселманнарны мөмкин кадәр көн буе гыйбадәт хәлендә тоту, яхшы вә саваплы эшләргә өндәүдер.

Адәм җомга көнне яратылган. Шуның өчен кеше бар ителгән бу көн изге көн дип кабул ителгән. Бу көнне бер-беребезне хөрмәтләү, гыйбадәт вә догалар кылып, Аллаһка рәхмәтебезне белдерү һәр мөселманның вазифаларыннандыр.

Җомга көнен һәм аннан алдагы төнне ничек уздырырга? Атнакич көнне икенде намазыннан алып, җомгага хәзерләнә башларга кирәк. Бу вакытта догалар кабул була. Таң ату белән госел тәһарәте алырга, чәч алдырырга (сакалны төзәтергә), тырнак кисәргә, чиста кием кияргә.

Җомгага каршы төндә һәм көндезен «Кәһеф» сүрәсен укысаң яхшы, һәм шулай ук Мөхәммәд Пәйгамбәргә (с.г.в.) күбрәк салават әйтергә кирәк. Хәдистә әйтелгән: «Иң кадерле көн - җомга көне, миңа багышлап күбрәк салават укыгыз, чөнки алар миңа килеп ирешә».

Кичтән үк ният итеп, җомга көнне ураза тоту сөннәт. Әмма бер көн генә ураза тотмаска, ә пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә, яисә җомга һәм шимбә көннәрендә тотарга кирәк. Сәдака өләшергә, якыннарыңны сөендерергә тырышырга, туганнарыңның, бигрәк тә әти-әниеңнең, авыру кешеләрнең хәлләрен белешергә, якыннарыңның каберләрен зиярәт итәргә, үзеңә һәм кунакларың өчен тәмле ризыклар белән табын хәзерләргә кирәк. Җомга көнне ахирәт эшләренә багышласаң яхшы була, шул чагында җомга көне атнаның бүтән көннәре өчен кәффарәт (гафу ителү) булып хезмәт итә. Шулай ук гыйлемле кешеләр динебез хакында әңгәмәләр алып барган мәҗлесләрдә катнашу да хәерле.

Үз акылында булган, азат һәм балигъ булган ирләр өчен җәмәгать белән җомга намазына катнашу фарыз була. Бу җомга намазы укылган торак төбәктә яшәгән ирләргә кагыла. Хәдистә әйтелгәнчә, кем җитди сәбәпсез (авыру һәм башкалар) өч тапкыр җомга намазын калдырса, шул кеше мөнафикъларда н санала.

*(“Ислам дине нигезләре”ннән)*

***СОРАУ-ҖАВАП***

**Сорау:** Әссәламү галәйкүм! Корбанны әҗәткә акча алып торып чалсаң ярыймы? Мин күптән түгел генә намаз укый башладым һәм корбан чалуның вәҗиб икәнлеген белдем. Аны ничек башкарырга икәнен әлегә белмим, ярдәм итегез әле.

**Җавап**: Үә галәйкүм әссәлам! Корбан бәйрәмендә сарык чалу һәр мөселманга мәҗбүри (вәҗиб). Әмма аның кайбер шартлары бар. Үзенең “Әл-Бахр Әр-Раик” хезмәтендә Ибн Нүҗәйм болай дип яза: “Нисапка җиткән малы булган, ерак сәфәрдә булмаган һәр мөселманга үзе исеменнән (баласы исеменнән түгел) Корбан көннәрендә бер сарык, яисә 7 кешегә бер сыер яки дөя чалу мәҗбүри”.

Бу билгеләмәне аңлатып китик. Корбан чалу мәҗбүри булсын өчен түбәндәге шартлар үтәлергә тиеш:

1. Ислам, ягъни корбан чалырга ниятләгән кешенең мөселман булуы.
2. Коллыктан азат булу.
3. Нисап. Әҗәтләрен санамыйча 595 грамм көмеш бәясендә малы булу. Нисап күләме ел саен үзгәрә, аның күләмен ел саен мәхәллә имамыннан белештерү тиешле.
4. Балигълыкка ирешү.

Билгеләмәдән аңлашылганча, кеше балалары өчен, балигълыкка ирешү-ирешмәвенә карамастан, корбан чалырга бурычлы түгел. Корбан сарыгы алыр өчен әҗәткә акча алып тору да тиешле гамәл түгел, чөнки югарыда күрсәтелгән шартларда нисап мәсьәләсе ачык аңлатылган.

*(ТР МДН фәтваларыннан)*

***ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ***

# “ҮЗЕҢӘ СОРАУ БИРЕРГӘ КИРӘК”

*Тәүбәгә килү нидән гыйбарәт, җан һәм тән ни рәвешле әманәт була – шул хакта Чаллы шәһәренең имам-мөхтәсибе **Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН** белән сөйләшәбез.*



**- Тел - сөяксез, сүзне чүпрә урынына кабарта-кабарта сөйли ала... Кичә генә эчкече булган берүнең намазга басканын, яки элек парторг булган кешенең дин юлына килүен күрсәләр, сокланасы урынга, бармак төртеп күрсәтү, кырыкка төрләндереп сөйләү башлана. Янәсе, менә шул кеше дә дингә килгән, имеш...**

- Бу сүзләрне күбрәк диннән читтә булган кеше әйтә, еш кына үзен аклау өчен. Чөнки теге кеше дингә килгән, ә бу кеше килмәгән, үзен акларга бер-бер сәбәп кирәк бит, шуңа да аның кимчелекләрен эзли башлый. Әмма бер кеше дә дөньяга фәрештә булып килмәгән. Әле диндә булмыйча, гөнаһлар кылган кеше, бервакыт акылына килеп, дин юлына, Аллаһ юлына керә, намазга баса, уразалар тота башлый. Элек үткәне өчен Аллаһы Тәгалә каршында тәүбә итә. Инде кылган начар гамәлләрен кабат эшләмәскә, туры юлга кереп, шушы туры юлдан гына барырга ихласлык белән ният итә. Андый кешенең теге тормышы, кылган гөнаһлары артта кала, ул яңа китапны ача, аны яңадан яза башлый. Аллаһы Тәгалә әгәр аның тәүбәләрен кабул итә икән, теләгән кешеләренең элекке гөнаһларын юк итә. “Кеше ни уйлый, кеше нәрсә әйтер”, дип, кеше сүзенә карарга кирәкми. Аллаһ нәрсә әйтер, Аллаһ нәрсә язар, тәүбәләрне кабул итәрме - үзеңә шул сорауны бирергә кирәк.

**- Әлфәс хәзрәт, әманәт турында аңлатып китсәгез иде. Әгәр тән һәм җан әманәт икән, бүген, замана шаукымына ияреп, хатын-кызның ирен кабартуы, пластик операцияләр ясатып яшәрергә омтылуы гөнаһлы гамәл саналамы? Җанны саклау нәрсәдән гыйбарәт?**

- Аллаһы Тәгалә безләргә тәнебезне дә, җаныбызны да әманәт итеп, вакытлыча итеп биргән. Тән дә кала, җан да китә. Биргән әйберен Аллаһы Тәгалә алачак. Кемгә нәрсә бирә - анысын Үзе белүче. Кемдер сау-сәламәт, кемдер чирләп йөри; кемгәдер авырлык килә...Тәнне саклау дигәндә, кеше үзенә бернинди зыян салырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә ничек биргән, ничек бар - шулай калырга тиеш. Ә инде җитешмәгән җире булса - табибка барып, төзәтергә була. Бер-бер кимчелеге тормышын алып барырга комачаулый икән, төзәтергә мөмкинлек бар икән - шәригатькә каршы килмәгәнне эшләргә мөмкин. Әмма ирен кабартып, каш ясатып һ.б. тәнне үзгәртеп йөрү - мөселманның гадәте түгел. Хатын-кыз үзенең ире өчен матурланса, бер хәл. Тик аларның күбесе урамга чыгып, үзен җәмгыятькә күрсәтү өчен эшли. Кияүдәге мөселман хатын-кыз бөтен матурлыгын үз ире алдында гына күрсәтә ала.

Җанны саклау дигәндә, үз-үзеңә кул салмау дибез. Бу хактагы сорау белән дә күп мөрәҗәгать итәләр. Мондый эшкә Аллаһтан курыкмаган, ахирәттә Аллаһның казасыннан курыкмаган, ахирәттә җәһәннәмнән курыкмаган кеше генә бара. Чын иманлы, чын ихласлы кеше беркайчан да моны эшләми, чөнки җәһәннәм әһеле, ут әһеле буласын белә. Җанны Аллаһы Тәгалә бирде, җанны алучы да - Аллаһы Тәгалә, аның рөхсәте белән фәрештәләр алалар, вакыты җиткән мәлдә. Кешенең үз-үзенә кул салуы исламда катгый тыелган. Дөньялыкта калган туганнарына күпме кайгы-хәсрәт китергәнне аңласа, ахирәттә үзенең урынын аңласа, әлбәттә, кеше сабыррак булыр иде.

*Әңгәмәдәш* - **Айгөл Әхмәтгалиева**

# Июль аена намаз вакытлары

| Милади июль | Көн исеме | Зөлкагыйдә, зөлхиҗҗә | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ясту Уфа | Ясту Чаллы | Ясту Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Пж | 21 | 02:44 | 00:50 | 01:03 | 03:16 | 01:20 | 01:33 | 04:44 | 02:50 | 03:03 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:56 | 20:17 | 20:30 | 23:26 | 21:47 | 22:00 |
| 2 | Жм | 22 | 02:44 | 00:51 | 01:04 | 03:16 | 01:21 | 01:34 | 04:44 | 02:51 | 03:04 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:56 | 20:17 | 20:30 | 23:26 | 21:47 | 22:00 |
| 3 | Шм | 23 | 02:45 | 00:52 | 01:05 | 03:17 | 01:22 | 01:35 | 04:45 | 02:52 | 03:05 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:20 | 17:34 | 21:55 | 20:16 | 20:29 | 23:25 | 21:46 | 21:59 |
| 4 | Як | 24 | 02:46 | 00:53 | 01:06 | 03:18 | 01:23 | 01:36 | 04:46 | 02:53 | 03:06 | 13:21 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:20 | 17:33 | 21:55 | 20:15 | 20:29 | 23:25 | 21:45 | 21:59 |
| 5 | Дш | 25 | 02:47 | 00:54 | 01:07 | 03:19 | 01:24 | 01:37 | 04:47 | 02:54 | 03:07 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:54 | 20:15 | 20:28 | 23:24 | 21:45 | 21:58 |
| 6 | Сш | 26 | 02:48 | 00:55 | 01:08 | 03:20 | 01:25 | 01:38 | 04:48 | 02:55 | 03:08 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:53 | 20:14 | 20:27 | 23:23 | 21:44 | 21:57 |
| 7 | Чш | 27 | 02:49 | 00:56 | 01:09 | 03:21 | 01:26 | 01:39 | 04:49 | 02:56 | 03:09 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:19 | 17:32 | 21:53 | 20:13 | 20:26 | 23:23 | 21:43 | 21:56 |
| 8 | Пж | 28 | 02:50 | 00:57 | 01:10 | 03:22 | 01:27 | 01:40 | 04:50 | 02:57 | 03:10 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:19 | 17:32 | 21:52 | 20:12 | 20:26 | 23:22 | 21:42 | 21:56 |
| 9 | Жм | 29 | 02:51 | 00:58 | 01:11 | 03:23 | 01:28 | 01:41 | 04:51 | 02:58 | 03:11 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:19 | 17:32 | 21:51 | 20:11 | 20:25 | 23:21 | 21:41 | 21:55 |
| 10 | Шм | 30 | 02:53 | 00:59 | 01:12 | 03:25 | 01:29 | 01:42 | 04:53 | 02:59 | 03:12 | 13:22 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:18 | 17:31 | 21:50 | 20:10 | 20:24 | 23:20 | 21:40 | 21:54 |
| 11 | Як | 1 | 02:54 | 01:01 | 01:14 | 03:26 | 01:31 | 01:44 | 04:54 | 03:01 | 03:14 | 13:22 | 11:35 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:18 | 17:31 | 21:49 | 20:09 | 20:23 | 23:19 | 21:39 | 21:53 |
| 12 | Дш | 2 | 02:55 | 01:02 | 01:15 | 03:27 | 01:32 | 01:45 | 04:55 | 03:02 | 03:15 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:17 | 17:30 | 21:48 | 20:08 | 20:22 | 23:18 | 21:38 | 21:52 |
| 13 | Сш | 3 | 02:56 | 01:03 | 01:16 | 03:28 | 01:33 | 01:46 | 04:56 | 03:03 | 03:16 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:00 | 17:17 | 17:30 | 21:47 | 20:07 | 20:20 | 23:17 | 21:37 | 21:50 |
| 14 | Чш | 4 | 02:58 | 01:05 | 01:18 | 03:30 | 01:35 | 01:48 | 04:58 | 03:05 | 03:18 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:00 | 17:16 | 17:29 | 21:46 | 20:06 | 20:19 | 23:16 | 21:36 | 21:49 |
| 15 | Пж | 5 | 02:59 | 01:06 | 01:19 | 03:31 | 01:36 | 01:49 | 04:59 | 03:06 | 03:19 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:59 | 17:15 | 17:29 | 21:45 | 20:05 | 20:18 | 23:15 | 21:35 | 21:48 |
| 16 | Жм | 6 | 03:00 | 01:08 | 01:21 | 03:32 | 01:38 | 01:51 | 05:00 | 03:08 | 03:21 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:59 | 17:15 | 17:28 | 21:43 | 20:03 | 20:17 | 23:13 | 21:33 | 21:47 |
| 17 | Шм | 7 | 03:02 | 01:09 | 01:22 | 03:34 | 01:39 | 01:52 | 05:02 | 03:09 | 03:22 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:58 | 17:14 | 17:27 | 21:42 | 20:02 | 20:15 | 23:12 | 21:32 | 21:45 |
| 18 | Як | 8 | 03:03 | 01:11 | 01:24 | 03:35 | 01:41 | 01:54 | 05:03 | 03:11 | 03:24 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:57 | 17:13 | 17:27 | 21:41 | 20:00 | 20:14 | 23:11 | 21:30 | 21:44 |
| 19 | Дш | 9 | 03:05 | 01:12 | 01:25 | 03:37 | 01:42 | 01:55 | 05:05 | 03:12 | 03:25 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:57 | 17:13 | 17:26 | 21:39 | 19:59 | 20:12 | 23:09 | 21:29 | 21:42 |
| 20 | Сш | 10 | 03:06 | 01:14 | 01:27 | 03:38 | 01:44 | 01:57 | 05:06 | 03:14 | 03:27 | 13:23 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:56 | 17:12 | 17:25 | 21:38 | 19:57 | 20:11 | 23:08 | 21:27 | 21:41 |
| 21 | Чш | 11 | 03:08 | 01:16 | 01:29 | 03:40 | 01:46 | 01:59 | 05:08 | 03:16 | 03:29 | 13:23 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:55 | 17:11 | 17:24 | 21:37 | 19:56 | 20:09 | 23:07 | 21:26 | 21:39 |
| 22 | Пж | 12 | 03:09 | 01:17 | 01:30 | 03:41 | 01:47 | 02:00 | 05:09 | 03:17 | 03:30 | 13:23 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:54 | 17:10 | 17:23 | 21:35 | 19:54 | 20:08 | 23:05 | 21:24 | 21:38 |
| 23 | Жм | 13 | 03:11 | 01:19 | 01:32 | 03:43 | 01:49 | 02:02 | 05:11 | 03:19 | 03:32 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:53 | 17:09 | 17:22 | 21:33 | 19:53 | 20:06 | 23:03 | 21:23 | 21:36 |
| 24 | Шм | 14 | 03:13 | 01:21 | 01:34 | 03:45 | 01:51 | 02:04 | 05:13 | 03:21 | 03:34 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:53 | 17:08 | 17:22 | 21:32 | 19:51 | 20:04 | 23:02 | 21:21 | 21:34 |
| 25 | Як | 15 | 03:14 | 01:22 | 01:35 | 03:45 | 01:52 | 02:05 | 05:14 | 03:22 | 03:35 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:52 | 17:07 | 17:21 | 21:30 | 19:49 | 20:03 | 23:00 | 21:19 | 21:33 |
| 26 | Дш | 16 | 03:16 | 01:24 | 01:37 | 03:48 | 01:54 | 02:07 | 05:16 | 03:24 | 03:37 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:51 | 17:06 | 17:20 | 21:29 | 19:48 | 20:01 | 22:59 | 21:18 | 21:31 |
| 27 | Сш | 17 | 03:18 | 01:26 | 01:39 | 03:50 | 01:56 | 02:09 | 05:18 | 03:26 | 03:39 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:50 | 17:05 | 17:19 | 21:27 | 19:46 | 19:59 | 22:57 | 21:16 | 21:29 |
| 28 | Чш | 18 | 03:19 | 01:28 | 01:41 | 03:51 | 01:58 | 02:11 | 05:19 | 03:28 | 03:41 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:49 | 17:04 | 17:18 | 21:25 | 19:44 | 19:57 | 22:55 | 21:14 | 21:27 |
| 29 | Пж | 19 | 03:21 | 01:29 | 01:42 | 03:53 | 01:59 | 02:12 | 05:21 | 03:29 | 03:42 | 13:23 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:48 | 17:03 | 17:16 | 21:23 | 19:42 | 19:55 | 22:53 | 21:12 | 21:25 |
| 30 | Жм | 20 | 03:23 | 01:31 | 01:44 | 03:55 | 02:01 | 02:14 | 05:23 | 03:31 | 03:44 | 13:23 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:47 | 17:02 | 17:15 | 21:22 | 19:40 | 19:53 | 22:52 | 21:10 | 21:23 |
| 31 | Шм | 21 | 03:24 | 01:33 | 01:46 | 03:56 | 02:03 | 02:16 | 05:24 | 03:33 | 03:46 | 13:23 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:46 | 17:01 | 17:14 | 21:20 | 19:38 | 19:51 | 22:50 | 21:08 | 21:21 |

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

Муенсасы энҗе-мәрҗән
Күрше кызы Иркәнең.
Бүләк иткәннәр үзенә
Бигрәкләр килешкәнен.



Бәлигълык яшенә җиткәч,
Муенсасын яшерер.
Озын җиңле күлмәк кияр
Һәм яулык бәйләп йөрер.

*Саулыгым-байлыгым*

## КАРЛЫГАН ЯФРАГЫ



Карлыган яфрагы витаминнарга һәм файдалы элементларга бай. Аның составында эфир майлары һәм фитонцидлар, С витамины күп. С витамины, антиоксидант ролен башкара, организмны картаюдан һәм авырулардан саклый. С витамины карлыган яфрагында 460 мг, бөреләрендә - 175 мг, чәчәкләрендә - 270 мг кадәр бар. Бу яфракны кара чәйгә өстәмә буларак та салалар. Болай эшләгәндә, гадәти чәйгә хуш ис өстәлә. Чәйнең файдасы да арта. Шулай ук аны аерым термоста да төнәтәләр. Грипп вакытында карлыган яфрагыннан чәй организмны ныгыту чарасы булып тора. Чәен әзерләү өчен, ике бал кашыгы киптерелгән яисә яңа өзелгән карлыган яфрагына бер стакан кайнар су салып, өстен каплап торабыз. 10-15 минуттан чәй әзер. Әлеге чәйне цистит, пиелонефрит, кан басымы авырулары, пародонтоз вакытында, шулай ук иммунитетны ныгыту өчен һәм антисептик чара буларак та кулланалар.

## *БЕЛДЕРУ*

Казанда яшәүче 33 яшьлек мөселман хатын-кызы мөселман ир-егет белән танышырга тели. 7 яшьлек кызы бар.

*Элемтә өчен телефон:* ***89655853601*** (Лилия)

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 1100**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**11 июнь 16 сәг.**
**фактта 11 июнь 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**